# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

2020 елның 10 июне 12№

Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибе хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы федераль законнар, 2017 елның 19 июлендәге 56 - ЗРТ номерлы «Муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүне алмаштыручы затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында»гы, 2017 елның 19 июлендәге 57 - ЗРТ номерлы «Муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүне алмаштыручы затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында»гы Татарстан Республикасы законнары, Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибен расларга. (Кушымта)

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз

көчендә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе, Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлеге башлыгы: М.Р.Галиуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АЛЬКЕЕВСКИЙ РАЙОН СЕЛО НИЖНЕЕ АЛЬКЕЕВО
ОГРН 1041635600940
СОВЕТ НИЖНЕАЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЬКЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНН 1606001156

Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлеге
Советының 2020 елның
10 июнендәге 12 номерлы
карарына кушымта

**Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибе**

1. Әлеге тәртип Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба - керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар) турында, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тәкъдим иткән өчен җаваплылык чараларын (алга таба – җаваплылык чаралары). куллану процедурасын регламентлый.

2. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы $7^{3\text{-}1}$ өлеше нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган белешмәләр биргән муниципаль вазыйфаларны биләүне алмаштыручы затларга түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, җирле үзидарәнең сайланулы органы вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты беткәнче, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итү;

3)даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылык чараларының берсе буларак куллану

турындагы мәсьәлә Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советы (алга таба – Совет) тарафыннан карала.

Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен Татарстан Республикасы Президентының муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 40 статьясындагы $7^3$ өлешендә каралган җаваплылык чараларын куллану турындагы Советка кергән гаризасы нигез булып тора.

4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы Совет тарафыннан кергән көннән өч айдан да соңга калмыйча карала.

5. Совет муниципаль вазыйфаны биләүче затка, аңа карата күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кадәр биш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә язма рәвештә җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау турында хәбәр итә.

Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның килмәве Татарстан Республикасы Президентының җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карауга комачауламый.

6. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президентының гаризасы Совет утырышында Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советының Регламентында (алга таба – Регламент) билгеләнгән тәртиптә карала.

Күрсәтелгән мәсьәләне караганда муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка тапшырылган мәгълүматлар буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазыйфа биләүче затка карата куллану мәсьәләсе каралганда, җаваплылык чараларының берсе – депутатлар тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча таләпләр үтәлергә тиеш. Совет утырышында рәислек итүче депутатларга мәнфәгатьләр каршылыгының барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу максатларында, мәнфәгатьләр конфликтын яклаучы депутат карар кабул итүдән рәислек итүче тарафыннан читләштерелә.

7. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында Карар кабул ителә.

Әлеге карар Регламентта билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Татарстан Республикасы Президенты гаризасында күрсәтелгән депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. Җаваплылык чараларын куллану турындагы карар гаделлек, тиңлек пропорциональлек һәм котылгысызлык принциплары нигезендә, кылынган коррупцион хокук бозуның характерын, авырлыгын, кылынган хәлләрнең шартларын исәпкә алып, шулай ук, муниципаль вазыйфаны (вәкаләтләрен) биләүче зат тарафыннан муниципаль вазыйфаны, вазыйфаи бурычларын

(вәкаләтләрен) үтәлешенең алдагы нәтиҗәләрен, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән башка чикләүләр, тыюлар һәм бурычларны үтәвен исәпкә алып кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен бары тик бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупцион хокук бозу турындагы күрсәтмә, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актларның нигезләмәләре, карарга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирү хокукы турындагы язма булырга тиеш.

10. Җаваплылык чараларын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның нигезләнгән дәлиле булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфа биләүче затка имза астында тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чараларын куллану турындагы карарны муниципаль вазыйфаны биләүче затка җиткереп булмаса яисә күрсәтелгән зат карарга имза куюдан баш тартса, Әлки муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе җаваплылык чараларын куллану турындагы карар белән югарыда күрсәтелгән затның танышудан баш тартуы яки аңа мондый карар турында хәбәр итә алмавы турында акт төзи.

12. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.